ИНСПЕКЦИЯ
ГОСУДАРСТВЕННОГО
СТРОИТЕЛЬНОГО НАДЗОРА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ДӘҮЛӘТ ТӨЗЕЛЕШЕН
КҮЗӘТҮ ИНСПЕКЦИЯСЕ

ПРИКАЗ | БОЕРЫК

25.02.2016 Казан ш. № 16

**Татарстан Республикасының Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм бүтән оешмаларның мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен кабул итеп алу тәртибе турында нигезләмә раслау хакында**

2004 елның 27 июлендәге “Россия Федерациясендә дәүләт гражданлык хезмәте турында” № 79-ФЗ Федераль законның 17 статьясының 1 өлешендәге 11 пункты, Россия Федерациясе Президентының 2015 елның 10 октябрендәге “Россия Федерациясенең аерым дәүләт вазифаларын, федераль дәүләт хезмәтенең аерым вазифаларын биләүче затлар тарафыннан чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм башка оешмаларның мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен һәм бүтән аерымлык билгеләрен кабул итеп алу тәртибе турында нигезләмә раслау хакында” № 506 Указы һәм Татарстан Республикасы Президентының 2016 елның 12 гыйнварындагы “Аларга билгеләп кую һәм алардан азат итү Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан башкарыла торган Татарстан Республикасы дәүләт вазифаларын биләүче затлар тарафыннан чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм башка оешмаларның мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен һәм бүтән аерымлык

билгеләрен кабул итеп алу тәртибе турында нигезләмә раслау хакында” № УП-5 Указы нигезендә

**боерык бирәм:**

1. Кушымта булып килүче Татарстан Республикасының Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм бүтән оешмаларның мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен кабул итеп алу тәртибе турында нигезләмәне расларга.
2. Дәүләт хезмәте мәсьәләләре һәм кадрлар сәясәте буенча бүлеккә Инспекциянең дәүләт гражданлык хезмәткәрләрен һәм алар белән хезмәт контрактларын төзегәндә гражданнарны шушы боерык белән таныштырырга.
3. Хокукый идарәнең юридик бүлегенә әлеге боерыкның дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.
4. Боерык үтәлешен контрольдә тоту җаваплылыгын үз өстемә алам.

**Башлык** **В.А.Кудряшов**

Татарстан Республикасы Дәүләт
төзелешен күзәтү инспекциясе
башлыгының
2016 елның “25” 02
№ 16 боерыгы белән
расланды

**Татарстан Республикасының Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм бүтән оешмаларның мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен кабул итеп алу тәртибе турында**
**нигезләмә**

1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасының Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясендә (алга таба – Инспекция) Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан (алга таба – гражданлык хезмәткәре) чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм бүтән оешмаларның мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен кабул итеп алу тәртибен билгели, әгәр дә гражданлык хезмәткәренең вазифаи вәкаләтләре аталган оешмалар һәм берләшмәләр белән хезмәттәшлек итүгә караса (алга таба – исемнәр, бүләкләр).

2. Гражданлык хезмәткәре исемнәр, бүләкләр алганда Инспекция башлыгының ризалыгын алырга бурычлы.

3. Исем, бүләк, яисә чит дәүләттән, халыкара оешмадан, сәяси партиядән, бүтән иҗтимагый берләшмәдән, дини берләшмәдән киләчәктә аларны алу турында хәбәр алган гражданлык хезмәткәре өч эш көне дәвамында кадрлар сәясәте бүлегенә Инспекция башлыгы исеменә чит дәүләтнең, халыкара оешманың, сәяси партиянең, бүтән иҗтимагый оешманың, бүтән оешманың мактаулы яки махсус исемен, бүләген кабул итүне рөхсәт итүе турында шушы Нигезләмәгә карата 1 кушымтадагы үрнәк буенча төзелгән үтенечнамә (алга таба – үтенечнамә) тапшыра.

4. Исемнән, бүләктән баш тарткан гражданлык хезмәткәре өч эш көне дәвамында кадрлар сәясәте бүлегенә Инспекция башлыгы исеменә шушы Нигезләмәнең 2 кушымтасындагы үрнәк буенча чит дәүләтнең, халыкара оешманың, сәяси партиянең, бүтән иҗтимагый оешманың, бүтән оешманың мактаулы яки махсус исемен, бүләген алудан баш тарту турында белдерүнамә (алга таба – белдерүнамә) тапшыра.

5. Исем, бүләк алган гражданлык хезмәткәре, Инспекция башлыгы үтенечнамәне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча карар кабул иткәнчегә кадәр, исемгә карата документларның төп нөсхәләрен һәм бүләккә карата документларның төп нөсхәләрен кадрлар сәясәте бүлегенә аларны алганнан соң өч эш көне дәвамында җаваплы саклау өчен тапшыра. Шул ук вакытта

әлеге Нигезләмәнең 3 кушымтасындагы үрнәк буенча кабул итеп алу-тапшыру акты төзелә.

6. Хезмәт командировкасы вакытында гражданлык хезмәткәре исем, бүләк алган очракта яки алардан баш тартканда, үтенечнамәне яки белдерүнамәне тапшыру вакыты дәүләт хезмәткәренең хезмәт командировкасыннан кайткан көненнән башлап исәпләнә башлый.

7. Әгәр дә гражданлык хезмәткәре, аңа бәйле булмаган сәбәпләр аркасында үтенечнамәне яки белдерүнамәне, исемгә карата документларның төп нөсхәләрен һәм бүләккә карата документларның төп нөсхәләрен шушы Нигезләмәнең 3-5 пунктларында күрсәтелгән вакытта тапшыра алмаса, ул үтенечнамәне яки белдерүнамәне, исемгә карата документларның төп нөсхәләрен һәм бүләккә карата документларның төп нөсхәләрен мондый сәбәпне юкка чыгарганнан соң килүче эш көненнән соңга калмыйча тапшырырга тиеш.

8. Үтенечнамәне карап тикшерүне тәэмин итү, Инспекция башлыгына үтенечнамә тапшырган затка үтенечнамәне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Инспекция башлыгы тарафыннан кабул ителгән карар турында хәбәр итү, шулай ук белдерүнамәләрне исәпкә алу эше дәүләт хезмәте мәсьәләләре һәм кадрлар сәясәте буенча бүлек тарафыннан башлык билгеләгән тәртиптә гамәлгә ашырыла. Үтенечнамә (белдерүнамә) шушы Нигезләмәнең 4 кушымтасындагы үрнәк буенча төзелгән теркәү дәфтәрендә кергән көнендә теркәлә.

9. Дәүләт гражданлык хезмәткәренең шушы Нигезләмәнең 5 пунктында атлаган үтенечнамәсе башлык тарафыннан канәгатьләндерелгән очракта, дәүләт хезмәте мәсьәләләре һәм кадрлар сәясәте буенча бүлек 10 көн дәвамында дәүләт гражданлык хезмәткәренә исемгә карата документларның чын нөсхәләрен, бүләкне һәм аңа карата документларның чын нөсхәләрен тапшыра.

10. Инспекция башлыгы дәүләт гражданлык хезмәткәренең шушы Нигезләмәнең 5 пунктында күрсәтелгән үтенечнамәсен канәгатьләндермәгән очракта, дәүләт хезмәте мәсьәләләре һәм кадрлар сәясәте буенча бүлек дәүләт гражданлык хезмәткәренә бу хакта хәбәр итә һәм 10 эш көне дәвамында исемгә карата документларның төп нөсхәләрен, бүләкне һәм бүләккә карата документларның төп нөсхәләрен чит дәүләтнең тиешле органына, халыкара оешмага, сәяси партиягә, бүтән иҗтимагый берләшмәгә яки башка оешмага җибәрә.

Татарстан Республикасының Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм бүтән оешмаларның мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен кабул итеп алу тәртибе турында нигезләмәгә карата

1 кушымта

Татарстан Республикасының Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе башлыгына
________________________________________

кемнән _________________________________
(Ф.И.А., били торган вазифа)
________________________________________
________________________________________
(Ф.И.А., телефон номеры)

Чит дәүләтнең, халыкара оешманың, сәяси партиянең, бүтән иҗтимагый оешманың һәм бүтән оешмаларның мактаулы яки махсус исемен, бүләген кабул итүне рөхсәт итү турында
үтенечнамә

Миңа түбәндәгеләрне кабул итәргә рөхсәт бирүне сорыйм________________

________________________________________________________________________
(мактаулы яки махсус исемнең, бүләкнең исеме)
________________________________________________________________________
(нинди хезмәтләр өчен һәм кем тарафыннан бирелгән, нинди хезмәтләр өчен, кем тарафыннан бүләкләнгән)
________________________________________________________________________ .
(мактаулы яки махсус исемгә, бүләккә документларны тапшыру датасы һәм урыны)

Мактаулы яки махсус исемгә документлар, бүләк һәм аңа карата документлар: (кирәклесенең астына сызарга)____________________________________
________________________________________________________________________
(мактаулы яки махсус исемнең аталышы, бүләкләр)
________________________________________________________________________
(мактаулы яки махсус исемгә, бүләккә карата документларның исеме)

20___ елның “__”________ №______ кабул итеп алу-тапшыру акты нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе башлыгына тапшырылды.

“__”________ 20__ ел _______________ _______________________
(имза) (имзаның аңлатмасы)

Татарстан Республикасының Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм бүтән оешмаларның мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен кабул итеп алу тәртибе турында нигезләмәгә карата

2 кушымта

Татарстан Республикасының Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе башлыгына

______________________________________

кемнән ________________________________
(Ф.И.А., били торган вазифа)
_____________________________________________
_____________________________________________
(Ф.И.А., телефон номеры)

Чит дәүләтнең, халыкара оешманың, сәяси партиянең, бүтән иҗтимагый оешманың һәм бүтән оешмаларның мактаулы яки махсус исемен, бүләген кабул итүдән баш тарту турында белдерүнамә

_______________________________________________________________
(мактаулы яки махсус исемнең, бүләкнең исеме)
_______________________________________________________________.
(нинди хезмәтләр өчен һәм кем тарафыннан бирелә, нинди хезмәтләр өчен һәм кем тарафыннан бирелә)

алудан баш тарту турында минем тарафтан кабул ителгән карар турында хәбәр итәм.

“__”________ 20__ ел _______________ _______________________
(имза) (имзаның аңлатмасы)

Татарстан Республикасының Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм бүтән оешмаларның мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен кабул итеп алу тәртибе турында нигезләмәгә карата

3 кушымта

Татарстан Республикасының Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе башлыгына
______________________________________

кемнән ______________________________
(Ф.И.А., били торган вазифа)
______________________________________
______________________________________
(Ф.И.А., телефон номеры)

Кабул итеп алу-тапшыру
акты

“___” ___________ 20__ел                                                  № ____________

Без, түбәндә имза салучылар, түбәндәгеләр хакында акт төзедек:
______________________________________________________________________
(Ф.И.А., вазифа) тапшырды/кабул итеп алды (кирәклесе астына сызарга),

ә административ-хуҗалык тәэминат, гражданлык обронасы һәм дәүләт сатып алулары _________________________ (Ф.И.А.) түбәндәгеләрне тапшырды/кабул итеп алды (кирәклесенең астына сызарга):

| № п/п | Аталышы | Саны (данә) | Тасвирлама |
|---|---|---|---|
| 1. | | | |
| 2. | | | |

Тапшырды
_________________________________
(имза)                    (имзаның аңлатмасы)

Кабул итеп алды
_________________________________
(имза)                    (имзаның аңлатмасы)

Татарстан Республикасының Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм бүтән оешмаларның мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен кабул итеп алу тәртибе турында нигезләмәгә карата

4 кушымта

# Үтенечнамәләрне (белдерүнамәләрне) исәпкә алу ДӘФТӘРЕ

| № | Үтенечнамә (белдерүнамә) тапшырган гражданлык хезмәткәренең Ф.И.А. | Үтенечнамә (белдерүнамә) тапшырган гражданлык хезмәткәренең вазифасы | Үтенечнамә (белдерүнамә) кергән көн | Бүләкнең, исемнең аталышы | Кабул итеп алу-тапшыру актының реквизитлары (булган очракта) | Аның үтенечнамәсен (белдерүнамәсен) кабул итеп алган затның Ф.И.А. | Үтенечнамә (белдерүнамә) биргән затның имзасы, Ф.И.А. | Башлыкның карары турында мәгълүмат |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | | | | | | | | |
| 2 | | | | | | | | |